

КАДЕРЕ БАРМЫ?
400 кв. метр объектның хуҗасы юк

> 2

ИКЕСЕНӘ БЕР
Аларның шатлыклары да, кайгылары да уртак

> 3

СӘХНӘ ҺӘМ ГАДЕЛЛЕК
Фонограммага куелган концертларны депутатлар да тикшермәкче

> 4

61 НЧЕ ТАПКЫР
Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә көрәш турниры быел да Казанда узачак

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 10 (29170) | Чәршәмбе | 24 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ӨЙДӘ БУРАН БУЛМАСЫН

ТАБИГАТЬ КЫЛАНМЫШЛАРЫ КЕСӘГӘ СУГА

Кыш кышлыгын итте. Туңдык та, буранда адаша да яздык. Урамнарны баскан кар көртләрен тиз генә җиңәм, димә! Һава торышы бик салкын көннәрдә Татарстанда җылылык та шактый күп тотылган, дип кисәткәннәр әнә. Бу кыштан тагын нәрсә көтәсе?

ru.freepik.com

Синоптиклар кыек атып туры китерде. Һава торышын ун көннән дә ераккарак фаразларга яратмасалар да, көздән үк аномаль кыш турында кисәтүләре хак булды. Кышның башланмаган бер ае бар, ә ул инде борынны өшетерлек салкыннары белән дә, күз ачмаслык бураннары белән дә туйганчы сынады. Урамда һава торышы бозылган саен: «Әле ярый җылы өебез бар», – дип, кат-кат шөкер иттек. Әллә шуңамы, бу айда декабрь өчен килгән счет-фактура кәгазьләрен дә күпчелек артык дәшми-нитми генә түләү ягын карады. Югыйсә ел да гыйнварда кышның беренче аенда тотылган җылылык өчен исәп-хисап ясалган зур түләүләр килеп төшкәч, зар елаучылар саны бермә-бер арта иде. Быелгы кыш сабак бирде. Узган декабрьдә Татарстанның кайбер районнарында 49 градуска кадәр суытты.

Ут яккан, торбаларны җылыткан өчен түләргә туры киләчәк, әлбәттә. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, узган декабрьдә һава торышы кискен суыну сәбәпле, җылылык энергиясе күбрәк сарыф ителгән. Шуңа күрә декабрь өчен счет-фактура кәгазьләрендәге сумманың алдагы айныкыннан күбрәк булуына аптырыйсы юк. «Ноябрь белән чагыштырганда, Казанда җылылык – 34,6, Чаллыда – 56,9, Түбән Камада 50 процентка күбрәк тотылган», – диделәр министрлыкның матбугат хезмәтендә. Торбаларны җылытуга киткән чимал күпмегә артса, түләү дә якынча шулкадәр кыйммәтләнгән.

«ВТ» хәбәрчесе үз мисалында тикшереп карады. Ноябрь аенда өч бүлмәле фатирга җылылык өчен 3151 сум акча исәпләгән булсалар, декабрьдә әлеге төр түләү – 4359 сум. Салкын декабрь 30 процентка диярлек кыйммәтрәккә төшкән.

Билгеле булганча, бу кышта ут һәм су өчен 2022 елның декабрендә үк расланган тарифлар буенча, ягъни былтыр ничек түләсәк, шулай исәп-хисап ясыйбыз. Бер ел ярымлык «тынлык»тан соң бәяләр кабат 2024 елның 1 июлендә кыйммәтләнәчәк.

Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрының беренче урынбасары Алексей Фролов әйтүенчә, торак йортлардагы торбалардагы җылылыкны һава торышына карап көйлиләр.

– ТКХ тармагы хезмәткәрләре һава температурасына бәйле үзгәрешләрне даими тикшереп тора. Моның нәтиҗәсе буларак, декабрьдә көннәр кискен суытып җибәргәч тә, өйләр суынмады. Республикада яшәүчеләрне җылылык белән тәэмин итү эше өзлексез алып барылды, – диде ул.

Авылда, шәхси йортларда яшәүчеләр исә үзләрен үзләре кайгырта.

– Ноябрь белән чагыштырганда, декабрьдә өч бүлмәле өй өчен газга якынча 1 мең сумга күбрәк акча түләдем, – ди Яшел Үзән районының Норлат авылында яшәүче Сания Мансурова. – Балалар шәһәрдә тора. Өйдә үзем генә булгач, газны бераз кысып та куям. Түлисе бар дип салкында да утырмыйбыз, әлбәттә. Күпме кирәк, шулкадәр ягабыз. Аның каравы хәзер урамда кар көрәп җылынабыз. Бураннан соң ишегаллары кар гына. Урамны көн саен диярлек трактор чистартып китә. Анысы өчен борчыласы юк.

Ә менә шәһәр халкының күңеленә шом кергән. Карга чумган ишегалларын чистарткан, кар чыгарган өчен киләсе айда түләү артмасмы, дип шалтырата укучыларыбыз. Татарстанның ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов әйтүенчә, юкка борчылалар:

> Күп итеп кар яуды дип кенә милек хуҗалары ишегалдыннан кар чыгарган өчен өстәп акча түләргә тиеш түгел. Идарәче оешма моны тиктомалдан гына эшли дә алмый. Счет-фактура кәгазенә ишегалдыннан кар чыгаруга бәйле өстәмә юл кертү өчен, иң элек милекчеләр арасында җыелыш үткәрергә, алардан рөхсәт алырга кирәк. Күмәк ризалык юк икән, түләү дә юк. Шунысын да әйтергә кирәк: ишегалдыннан кар чыгару без түли торган «йорт тирәсен тәртиптә тоту»га кагылмый. Анда карны эттерү, юлны чистарту, ком-боз катнашмасы сибү, җәяүлеләр юлын себерү керә, ә карны читкә чыгару – юк. Ягъни моңа акча аерым каралмаган. Ишегалдыннан кар чыгаруны идарәче оешма үзе хәл итә. Без исә милек хуҗалары буларак, йорт тирәсен тәртиптә тотуны таләп итәргә хокуклы.

Казан мэры Илсур Метшин яуган карны җыештырып бетерергә ике атналап вакыт кирәк булачагын әйтте инде.

Сүз уңаеннан, быелгы җәй дә гайре табигый булачак, диләр. Нишлисең бит, без күрәсен кеше күрмәс...

Спорт кына түгел бу

Беренчесе һәм безнеке

Бик тиздән Татарстан башкаласы кешелек тарихында беренче мәртәбә оештырыла торган «Киләчәк уеннары» халыкара турнирын кабул итәчәк. Яңача, заманча, моңарчы күрелмәгән тамаша вәгъдә итә оештыручылар. Кемнәр килер? Нәрсә күрербез? Уеннар кайда узар? Ярышларга кадәр санаулы көннәр калганда бу хакта искәртү зыян итмәс.

НӘРСӘ БУ? «Киләчәк уеннары» халыкара чарасы беренче тапкыр үткәрелә. Бу ярышта спортның гадәти төрләре белән бергә санлы технологияләр кушылачак. Ягъни спортчыларга физик сәләтләрен дә, цифрлы юнәлештәге осталыкларын да күрсәтергә кирәк булачак. Ярышлар 21 дисциплина буенча узачак. Әйтик, фиджитал-футбол, фиджитал-баскетбол.

КАЙЧАН ҺӘМ КАЙДА? «Киләчәк уеннары» 21 февральдән 3 мартка кадәр узачак. Ярыш мәйданчыклары итеп Казандагы төрле спорт корылмаларын сайладылар. Әйтик, «Татнефть арена», яңа IT парк, шулай ук «Казан Экспо» үзәге.

НӘРСӘ ӨЧЕН ЯРЫШАЛАР? Спортчылар уеннарның трофее һәм 10 млн доллар акчалата приз өчен көч сынашачак. Әлеге акча турнир юнәлешләрендә җиңү яулаган спортчыларга биреләчәк. Турнирның трофее исә металл һәм акрилдан эшләнгән, аның эчендә уеннарның биш юнәлешен символлаштырган биш пластина бар (спорт, тактика, стратегия, тизлек, технология).

КЕМНӘР КИЛӘ? Ярышларда 2000ләп спортчы катнашыр дип көтелә. Катнашучыларның географиясе дә киң: Россиядән тыш, уеннарда чит ил киберспортчылары да катнаша.

«ЙОЛДЫЗ»ЛАР БУЛАМЫ? Әлеге ярышларның үз «йолдыз»лары булачак. Әйтик, уеннарның амбассадоры (илчесе) итеп җырчы Егор Крид сайланган. Моннан тыш Казанга футболчы Артем Дзюба, блогер Влад Бумага, киберспортчылар киләчәк. Хәтта ил Президенты Владимир Путинны да дәштеләр, аны да көтәләр.

БИЛЕТНЫ КАЙДАН АЛЫРГА? Билетларны махсус сайт аша сатып алырга мөмкин (tickets.gofuture.game). Бәясе 300 сумнан башлана. Уеннарның кайбер юнәлешләренә билетлар сатуга чыкты инде. Ярышларны онлайн да карап булачак, «Матч ТВ» каналы трансляция оештырачак. Алдан ук кисәтик: чараның ачылыш һәм ябылу тантаналарына билетлар сатылмаячак. Билетлар ике төрле булачак. Гадәти билет – трибунада утырып карау өчен. «Кунакчыллык программасы» дигәнен сатып алган очракта, билет иясе өчен парковка, ял, туклану зонасы һәм башка мөмкинлекләр ачылачак. Билгеле, соңгысының бәясе дә күпкә зуррак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сүзгә-сүз



Сергей ЛЕОНОВ, Россия Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау комитеты рәисе урынбасары:

Хәзерге вакытта хирург, анестезиолог-реаниматолог кебек белгечләргә кытлык күзәтелә. Алар – яшәү һәм үлем чигендә калган пациентларның гомерләре өчен көрәшүчеләр. Педиатрларга кытлык аеруча авылларда сизелә. Чөнки кеше бүген зур шәһәрләрне өстен күрә.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – БУРЫЧ

Россиядә яшәүчеләрнең 56 проценты бурычка акча алмаска тырыша. Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре сораштыру нәтиҗәсендә шуны ачыклаган. 20 ел элек бу күрсәткеч 36 процент булган.

КЕМНӘР БУРЫЧКА АЛМЫЙ?

18–24 яшьлекләр – 62%

60 яшьтән өлкәнрәкләр – 67%

АКЧА КИРӘКСӘ, НИШЛИ?

Туганнардан, якын дуслардан сорый – 55%

Банкка бара – 34%

Микрофинанс оешмасына мөрәҗәгать итә – 1%

Ачыклык кертелде

Россия Президенты Владимир Путин күпбалалы гаилә статусын федераль дәрәҗәдә билгеләүче һәм аңа каралган ярдәм чаралары күрсәтелгән яңа указга кул куйган. Указ нигезендә, өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләп үстерүче гаиләләр күпбалалы булып таныла. Моңа кадәр төбәкләр күпбалалы гаилә критериен үзләренчә билгели иде. Мондый гаиләләрдәге балаларга социаль ярдәм чаралары зурысына 18 яшь тулганчы (уку йортында көндезге бүлектә укыса, 23 яшь тулганчы) күрсәтелә. Аларга бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле пособиеләр түләү, хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә өстенлекләр, музейларга бушлай йөрү хокукы һәм башка ярдәм чаралары каралган.

Ашыгыч хезмәт

Узган елда Татарстанда яшәүчеләр 112 номерына якынча 3 миллион тапкыр мөрәҗәгать иткән. Шалтыратуларның 31 проценты – медицина ярдәмен сорауга, 18 проценты чамасы – җинаятьчелек турында, 5 проценты – юллардагы куркыныч очраклар турында хәбәр итүгә, 3 проценты – торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләренә, 1,5 проценты – янгын һәм 16 проценты белешмә мәгълүматларын сорауга туры килә.

Хезмәтнең ишарә телен белүче операторлары 46 мөрәҗәгатькә җавап биргән. Моннан тыш 112 психологлары 5600ләп консультация уздырган.

Гомумән алганда, 2009 елдан бирле хезмәт белгечләре барлыгы 22,1 миллионнан артыграк мөрәҗәгатьне кабул иткән һәм эшкәрткән. Быел 112нең бурычлары – Татарстанда «Киләчәк уеннары», «БРИКС илләренең спорт уеннары» һәм БРИКС илләре саммиты кебек зур халыкара чараларның иминлеген тәэмин итүгә үзләреннән өлеш кертү.

Өмет үзәге

Казанда яңа медицина оешмасы – Республика кризислы йөклелек үзәге ачылды. Дөрес, гыйнвар башында рәсми төстә ачылганчы, ул инде узган елның августыннан эшли башлаган. Хатын-кызлар консультацияләре табиблары бирегә йөклелектән котылырга ниятләүчеләрне җибәрә. Үзәктә акушер-гинекологлар, психолог, УЗИ табиблары, юристлар, социаль хезмәткәрләр эшли. Белгечләр хатын-кызны аборт ясатмаска өнди, йөклелек һәм бала тудыру турында барлык сорауларга җавап бирә, авыр чакларда ярдәмгә килә.

Биш ай эчендә медиклар үзәктә 218 хатын-кызны кабул иткән инде. Шуның 92се (41 проценты) йөклелекне саклап калырга булган.

Җепшетә

Татарстанда салкын һава кабат чигенә. Пәнҗешәмбе – 25 гыйнвардан кар яву, көннең җылытуы көтелә. Әмма КФУ метеорологы Тимур Әүхәдиев сүзләренә караганда, карның күпме явачагын әлегә әйтеп булмый.

Белгеч әйтүенчә, февраль аенда һава температурасының нормадан югары булуы фаразлана. Ягъни циклоннар өстенлек итәчәк, явым-төшем күп булачак.

Исегезгә төшерәбез: Казанда 17–22 гыйнварда – айлык норманың 106 проценты, гомумән, гыйнвар аенда норманың 159 проценты күләмендә кар яуган. Соңгы 14 елда рекордлы күрсәткеч бу. Шуннан соң Татарстанга буранга алмашка –28 градуска кадәр суык килде.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТЕТРӘҮЛЕ ҺӘМ ДАВЫЛЛЫ ДӨНЬЯ

2024 елның әле беренче ае да үтеп бетмәде, Җир шары дистә илләргә җитәрлек зур вакыйгалар сериясен кичереп өлгерде инде. Турбулентлык табигатьтә дә, җәмгыятьтә дә берьюлы күзәтелә. Дүшәмбедән сишәмбегә каршы төндә Кытай, Казахстан һәм Кыргызстан чик буе өлкәләрен ииләгән куәтле җир тетрәүләр булып үтте. Бу юллар язылган сишәмбе иртәсендә дә әле Күк асты иленда 7,3тән 4,5кә кадәрге магнитудалы тетрәнүләр дәвам итү турында хәбәрләр килеп тора. Кытай социаль тетрәнүләргә дә әзерләнә. Илнең фонд базары мәтәлчек ата. Соңгы 19 елда кытай акцияләренең болай ук түбән төшкәне юк иде әле, диләр.

Көнбатыш Европа «Иша» ураганы белән сынала. Бу юллар язылганда, Англия стихия иркендә иде. Британ икътисадында хәлләр шулай ук мөшкел. Begbies Traynor консалтинг компаниясе «киеренке финанс хәлендә»ге предприятиеләр саның икенче квартал рәттән артуын белдерде. Икътисадның барлык тармаклары да зыян күрә, ди ул. 47 меңнән артык британ предприятиесе җимерелү алдында тора.

Франциядәге хәлне бер җөмлә белән генә аңлатыйк. Француз фермерлары 22 гыйнварга каршы төндә Тарн һәм Гароннадагы атом электр станцияләрен камап алдылар.

Икътисад проблемаларының кискенләшүе зур сугыш куркынычы арту белән хәвефле. Көнбатыш коалиция әлегә халыклар игътибарын Якын Көнчыгыштагы Хәрби хәрәкәтләргә юнәлтергә тырыша. АКШ һәм Бөекбританиянең хәрби һава көчләре «Посейдон җәячесе» дигән исем астында Йәмәнне көчле утка тота. Европаның башка илләре дә бу операциягә кушылырга җыена. Югыйсә проблеманы тынычлык чигымсыз һәм гади юлы бар: Газзадагы вәхшилекне һәм аның блокадасын туктату. Израиль инде йөз көннән арткан сугышта 500дән артык сугышчы югалтуын белдерсә, «Әл-Җәзира», 10 меңнән артык сиончы солдат үтерелде, 30 меңнән артык яраланды, дип бара. Израильнең үзендә дә сугышка каршы хәрәкәт көчәя, әмма вәхшилекнең очы-кырые күренми әле. Хәрби җитәкчелек сугышны Ливанга җәелдерү ягында.

Көнбатышка каршы Якын Көнчыгыш каршылыгы да үсә, билгеле. Американың Гыйрактагы һәм Сүриядәге хәрби базалары даими утка тотыла. 23 гыйнварга каршы төнге сәгать бер тулып 8 минутта Сүриянең Дәйр-әл-Зор төбәгендә Американың Коноко хәрби базасында шартлау тавышлары яңгыравы турында видеохәбәр алдым.

Россиядә

БӘЯЛӘРНЕ СЫЕР ИТЕ БЕЛӘН ҮЛЧӘҮ

Гаҗәп түгел: Россия дә – башка дәүләтләр кичергән кыенлыклар зонасында. Әмма бездә халык сабыр: берәү дә, Мәскәү урамнарына алып барып, тирес түгәргә җыенмый. Үзенең тәртипле һәм акыллы тотарга законнар булыша. «Россиядә законнарның кырыслыгы аларның үтәлмәве белән йомшартыла» дигән кагыйдә күптән гамәлдән чыкты инде. Үтәләләр һәм ничек кенә әле! Дәүләт Думасы әнә артыгын сөйләүчеләрнең һәм кыланучыларның мал-мөлкәтен конфискацияләү турында закон кабул итәргә җыена. Әлегә ул проект хәлендә генә булса да, гамәлгә керәчәгенә шик юк. «Российская газета» сишәмбе санында әле табадан төшеп өлгермәгән канунга юрист аңлатмасын бирә.

Проблемалар ярсып һәм шаулап хәл ителми инде ул ителүен. Коммуналь тармакның җимерелүе әнә эпидемия рәвешендә ил буйлап җәелеп бара. Авариярләр саны артмаган ул үзе, әмма масштаблар киңәя. Инфраструктураның тузуы нәтиҗәсендә хәл катлаулана. Мәскәү өлкәсе губернаторы Воробьев тармакны җимерелү хәленнән чыгару өчен дистәләгән миллиард сум акча кирәк булачагын әйтте. Масштабны ил күләмендә зурайтып карагыз. Хакимиятләр эшләренең торышын алдан белмәгән дип әйтеп булмый. 2023 елның апрелендә үк өлкә губернаторы инфраструктураны яңарту өчен 300 миллиард сумлык программаны тормышка ашырачагын әйткән булган. Торбалар ул акчаны көтеп тормады, бары тик шуй була.

Түбән Новгородтагы нефть эшкәртү заводындагы аварияләр соң бензинның күпләп сату бәясе 12 процентка күтәрелгән. Хөкүмәт ягулык салу станцияләрендә бәяләрне үзгәрешсез тотарга тырыша. Заводның хуҗасы «Лукойл» үз ягулык станцияләренә бензинны читтән сатып ала башлаган. Бер компрессор җайланмасының авариясе генә дә шундый проблемалар тудыргач, масштаблар зураймасын дип дога кылырга гына кала.

Бәяләр дигәннән, Росстат аларны сыер ите белән үлчәп карый башлаган. Рәсмилек дәрәҗәсендәге бер рус газетасы: «Руководство Росстата уже давно измеряет цены на водку и продукты питания именно в килограммах говядины», – дип яза. Бәяләр үсештә инде, нишләтәсең. 2015 елдан 2022 елга кадәр атланмайның уртача бәясе 2,1 тапкыр арткан икән. Сыер ите – 55 процентка гына.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ: «БЕЗНЕҢ ДӘ ГАЕП БАР»

tatarstan.ru

Татарстанның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, узган елга йомгак ясап, агымдагы елга планнарны барлады. «ВТ» коллегиядә яңгыраган төп биш мәсьәләгә тукталды.

Керемнәр һәм бурычлар

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин сүзләренчә, узган ел Татарстанда дәүләт милкен кулланудан кергән керем 15,5 млрд сумны тәшкил иткән. Иң күп акча аренда түләүләре һәм җир участокларын кулланудан алынган. Тик шул ук вакытта бурычлар да бар. Узган ел аренда түләве буенча муниципаль бюджетларга бурыч 301 млн сумны тәшкил иткән. Аларның күп өлеше җир кишәрлекләренә туры килә. Милек буенча бурычлар 7 млн сумга кимесә, җир буенча әҗәтләр 40 млн сумга арткан. Бурычлылар исемлегендә беренче урыннарны Казан, Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Әгерҗе һәм Лаеш районнары алып тора.

Мондый очракларга карата Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов дәгъва эше (претензионная исковая работа) булырга тиешлеген әйтте.

Хуҗасызлык

Рөстәм Миңнеханов быел хуҗасыз җирләр һәм мөлкәткә бәйле проблемаларны да хәл итәргә кушты.

– Без барлык биналарның һәм торакларның хуҗаларын белергә тиеш. Шулай ук республикада шактый гына хуҗасыз объектлар һәм ташландык хәлдәге милек барлыгы ачыкланды. Министрлыкка район башлыклары белән берләп аларны муниципальләштерү буенча эш алып барырга, шулай ук кулланылмый торган барлык объектларны хуҗалы итүгә ирешергә кирәк. Минем мәгълүматлар буенча, алар 400 мең кв. метрдан күбрәк. Бу – җирле бюджетны арттыруның тагын бер мөмкинлеге, – диде ул.

Шулай ук Татарстан Рәисе авария хәлендәге дәүләт һәм муниципалитет милкенә дә игътибарны арттыру кирәклеген әйтте. Аларның саны 70 мең кв. метрдан артып киткән.

Ятимнәр

Ятим балаларга бирелә торган фатирларга һаман да кытлык бар. Узган ел республиканың махсус торак фонды алар өчен тагын 762 фатир белән тулыландырылган. Шулай итеп, бүген мондый фатирлар саны 3900гә җиткән. Алардагы тәртипне һәм торак-коммуналь түләүләренең вакытында түләнеп баруын һәрвакыт контрольдә тотарга туры килә. Тик республиканың 30дан артык районында мондый фатирларда бурычлар 56 млн сумга җиткән. Фәнил Әһлиуллин әйтүенчә, бурычлыларның күпчелеге беркайда да эшләми, башка милекләре юк, шуңа күрә әҗәтләрен алып та булмый.

Әлеге мәсьәләгә Рөстәм Миңнеханов та үз фикерен белдерде.

– Бер яктан караганда, без бик зур социаль бурычны хәл итәбез, әлеге балаларга шанс бирәбез. Икенче яктан, без моның үзебез теләгәнчә кабул ителмәвен күрәбез. Ләкин закон бар һәм аны үтәргә кирәк, – диде ул.

Билгеле булганча, Россия хөкүмәте 23 яшьтән зуррак булган ятим балаларга торак сертификатлары бирү тәртибен раслады. Быелдан алар аны бар уңайлыклары булган торак сатып алырга яки ипотеканы капларга тота алачак.

– Без алар турында тәртипсез, тормышка яраклашмаган дип фикер йөртә алабыз. Тик монда безнең дә гаеп бар. Димәк, без алар белән тиешенчә эшләмәгәнбез, – диде Татарстан Рәисе.

Күпбалалы гаиләләр

Узган елда мондый гаиләләргә 2600 җир участогы бирелгән. План үтәлсә дә, авырлыклар булган. 11 район (Әлмәт, Түбән Кама, Кукмара, Яшел Үзән, Биектау, Лениногорск, Алабуга, Зәй, Буа, Мөслим, Чүпрәле) куелган бурычларны үтәп чыга алмаганлыктан, алар өчен башкаларга тырышырга туры килгән. Ә менә Казан, Чаллы кебек шәһәрләрдә мондый гаиләләр өчен җир күләмен проблемалары кала бирә. Бүгенгә 17 мең участок табасы бар.

Җир кем кулында?

Коллегиядә авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать өчен каралган җирләрнең категориясен үзгәртү һәм алардан файдалану мәсьәләсенә дә тукталдылар.

– Монда безнең катгый система булырга тиеш: җир кемгә, кайчан һәм нинди максатлар өчен бирелә? Җир кучерелергә тиешле һәр проектны бертекләп анализларга кирәк, – диде бу уңайдан Рөстәм Миңнеханов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Җитди сөйләшү

Көндәлек игътибарда

Безнең гомуми бурыч – Татарстанны алга таба да халыкларыбызның мәдәниятләрен, традицияләрен ихтирам итүгә нигезләнгән тынычлык һәм татулык территориясе итеп калдыру. Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан Халыклар дуслыгы йортында узган «Түгәрәк өстәл» утырышында шулай диде. Чарада республиканың миграция сәясәтен тормышка ашыру мәсьәләләре каралды.

Парламент башлыгы, утырышны ачып, узган елда республикада Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы кысасында уздырылган чараларда актив катнашкан өчен милли иҗтимагый берләшмәләргә рәхмәт белдерде.

– Хәзерге вакытта бездә 262 җирле һәм төбәк милли-мәдәни иҗтимагый берләшмәсе бар. Алар 37 милләт вәкилләре мәнфәгатьләрен чагылдыра. Шул ук вакытта муниципалитетларда 13 Дуслык йорты һәм үзәге, ассамблеяның 38 филиалы һәм вәкиллеге эшләп килә, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Этносара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең төп үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: алар, аеруча бүгенге катлаулы хәлләрдә вазгыять шартларында, даими, көндәлек игътибар таләп итә.

Парламент башлыгы хезмәт миграциясе мәсьәләләренә аерым тукталып үтте.

– Татарстан икътисадый мөмкинлекләре, күпкырлы икътисады, тормыш дәрәҗәсе, килүчеләргә карата җылы мөнәсәбәте белән мигрантларны үзенә бик нык җәлеп итә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Без, үз чиратыбызда, эшче куллар, квалификацияле кадрлар, намуслы һәм әйбәт эшләүче кешеләр белән кызыксынабыз.

Хәзерге вакытта Татарстанда 70,5 меңнән артык чит ил кешесе миграция учетында тора. 17 меңгә якын кешенең вакытлыча яшәүгә рөхсәте бар. Шул рәвешле бүген республикада 87,4 мең мигрант яши.

Безгә алар асылда эшләргә килә. Чит ил кешеләренең 52 процентган артыгы эшкә урнашу мөмкинлеген республикага килүләренең төп максаты итеп саный. Узган елда оешмалар һәм предприятиеләр, 723 чит ил хезмәткәрен җәлеп итү өчен, 108 рөхсәт рәсмиләштергән. Эшләүгә 915 рөхсәт, 53 меңгә якын патент бирелгән.

Моннан тыш республика вузларында 26 меңләп чит ил студенты белем ала, аларның саны артканнан-арта.

Дәүләт Советы Рәисе Гражданлык җәмгыятен үстерү һәм кеше хокуклары буенча совет утырышы йомгаклары нигезендә Россия Президенты Владимир Путин куйган бурычларны да искә төшереп узды. Биредә сүз, аерым алганда, мигрантларның балаларын социаль, мәдәни һәм тел ягыннан җәмгыятькә җайлаштыру тәкъдимнәрен әзерләү турында бара.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, Дәүләт Советы Россиянең миграция турындагы законына төзәтмәләр кертүне тәкъдим итәргә ниятли. Дәүләт Советы депутатлары, чит ил гражданнары илгә кергәннән соң 13 көн эчендә укуга яки эшкә керешмәгән очракта, аларның бездә яшәүләрен туктатырга кирәк, дип саный. «Килүгә үк, алар вузда яки предприятиедә теркәлергә тиеш, – дип басым ясап әйтте парламент башлыгы. – Ә кына чит ил кешеләре безгә килгәч, эшкә дә урнашмый, укымый да. Һәм аларның нәрсә белән шөгыльләнүен беркем дә белми». Республика тәкъдиме Федераль Җыен каршындагы Закон чыгаручылар советына җибәрелгән инде.

Утырышта республика прокуроры Альберт Суяргулов, Россия Тикшерү комитетының Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Валерий Липский һәм башка ведомстволар җитәкчеләре катнашты. Анда ил Президентын сайлау кампаниясен үткәрү мәсьәләләре дә каралды.

ҖАВАБЫН ҮЗЕҢ ТОТАСЫ

Нәтиҗә

2023 елда табигатьне саклауга 10,3 млрд сум акча тотылган. Эшләгән эшләр дә шактый. Су төбендә тик яткан әллә кайчангы нефть торбалары чыгарылган, Самосырово чүплеге бетерелеп, инде хәзер андагы калдыклардан электр энергиясе ала башлаячаклар. Ләм басуларындагы эшләр дә тәмамланып килә. Әлеге һәм башка эшләр турында Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының еллык киңәйтелгән утырышында сөйләделәр. Министр Александр Шадриков сүзләренчә, алар халыктан килгән һәр сорауга җавап табарга тырышалар. Татарстанда яшәүчеләрнең бер генә зары да булырга тиеш түгел, ди алар.

Казанның Гудованцев урамында бер урынга 88 миллион сумлык зарар килгән.

Зар дигәннән, 2023 елда һавада начар исләр бар дип шалтыратучылар күп булган. Казанның Авиатөзелеш, Мәскәү районнары, «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләрдән 910 мөрәҗәгать килгән. Барысы да һаваның чисталыгына кагылышлы.

– Атмосфера сыйфатын тикшереп тору өчен, без махсус автомат станцияләр куйдык. Татарстанда шундый 17 станция эшли. Шул рәвешле без һавадагы күрсәткечләрне 4 миллионнан артык тикшердек инде, – ди Александр Шадриков.

Совет районында урнашкан Самосырово бистәсендә яшәүчеләр дә моңа кадәр зарланган. Мөрәҗәгать итүчеләрнең саны 300гә җиткән була. «Экология» илкүләм проекты кысасында әлеге чүплектән һәм сасы истән котылалар. Быелга Саба районының Шәмәрдән бистәсендә нефть аккан җирләрне чистартып бетерәселәре бар.

– Татарстанда 55 полигон исәптә. Шуның 34е эшли, 21е ябылды. Шуңамы, чүплекләр баш калкыта. Былтыр без тиешсез урыннардагы 2193 чүплекне юкка чыгардык. Күп очракта калдыклар вакытында ташланмый, – ди министр.

Ә менә чүпне яр буйларына ташлап китүчеләр бар. Экологлар кайберләренең эзенә дә төшкән. Дәрвишләр бистәсендә күпбалалы гаиләләргә бирелгән җир мәйданнарына чүп китереп түккәннәр, 58 миллион сумлык зыян салынган. Александр Шадриков әйтүенчә, күп вакытта гаеплеләрне табып булмый.

– Табигатькә зыян салучы җавабын үзе тотсын иде, – ди ул.

Зыян дигән, министр республика елгаларына начар калдыклар агызып ятучы оешманы да атады, җир асты казылмаларына зыян салучыларны, аннан рөхсәтсез файдаланучыларны да әйтте.

Татарстанда елгаларны чистарту дәвам итә. Узган ел Мамадыш районындагы Бөрсет елгасы төбеннән 65 мең кубометр чүп-чар чыгарганнар. Әлеге эшләр «Экология» илкүләм проектының «Уникаль сулыкларны саклау» федераль проекты кысасында башкарылган. Елганы чистартуга федераль бюджеттан 113,2 миллион сум акча бүлеп бирелгән.

Утырышта Иделне савыктыруга да тукталдылар. Республикада биологик чистарту корылмаларын яңарту эшләре дәвам итә. Министр сүзләренчә, аларны төзекләндереп, экологлар Татарстан башкаласында яшәүче 1,3 миллион кешенең яшәү шартларын яхшырта.

– Татарстанда сулыкларда тик ятучы нефть торбаларын чыгару эшләре тәмамланды. 23,7 чакрымга сузылган торбаларны җир өстенә чыгардык. Моны тормышка ашыру өчен 930,5 миллион сум акча тотылды. Нинди генә эшкә тотынма, республика җитәкчелеге, бизнес вәкилләре, фән, җәмәгать эшлеклеләре белән бергә киңәшләшергә кирәк. Бары тик шул вакытта гына уңышка ирешеп була, – диде Александр Шадриков.

2023 ел Иделдә су кимеп, Куйбышев сусаклагычының аяның хәле белән исгә калды. Александр Шадриков бу хакта күп сөйләде инде. Махсус комиссия булдырып, күрше-тира биш төбәк тә бергә эшли башладылар. Максатлары – суны тиешле биеклеккә күтәрү. Татарстанның Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин да 2024 елга шушы бурычны куйды.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САКЛАНЫР ЧАК

Көн кадагында

Татарстанда грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны югары дәрәҗәдә саклана. Елның беренче атнасында гына да грипп һәм ОРВИ йоктыруның 17593 очрагы теркәлгән иде. Ишеп яуган кары, аның артыннан ук кисәк килгән суыклары белән аерылып торган бу көннәрдә сәламәтлекне дә сакларга кирәк, дип искәртә табиблар.

Һава торышы кисәк үзгәргән көннәрдә ул аеруча саклауга мохтаҗ. Белгечләр, быел грипп та алдагы елларга караганда күпкә мәкерлерәк, дип искәртә. Аның белән авырып терелүчеләр арасында йөрәге, үпкәсе зәгыйфьләнеп калучылар шактый икән. Татарстанның баш терапевты Диана Габделганиева сүзләренә караганда,ируслы чирләрдән саклану өчен, прививка ясатудан да яхшысы юк. Кеше күп җыелган урыннарга битлек кимичә чыкмаска, кулларны-битләрне һәрчак юып торырга, урамнан кергәч, борын белән

Илдар Мөхәммәтҗанов

авызны яхшылап чайкатырга кирәк. Бүлмәләрне җилләтеп торырга да онытмагыз. Авырый торган кеше белән аралашырга туры килсә, алда әйтелгән киңәшләрдән тыш, борынга дару тамызып кую да артык булмас, – ди белгеч.

Республикада грипп һәм ОРВИ белән авыручылар арту сәбәпле, бу көннәрдә халыктан килгән мөрәҗәгатьләрне сәламәтлек буенча бердәм элемтә үзәгендә дә кабул итә башлаганнар. Шул рәвешле, 8(843) 558-03-03 номерына шалтыратып, өйгә табиб чакыртырга мөмкин. Прививка ясату, диспансеризациягә бәйле сораулары булган кешеләр дә шушы номер буенча мөрәҗәгать итә ала. Элемтә үзәге ачылганнан бирле анда 16 меңнән артык шалтырату килеп ирешкән. Билгеле булганча, әлеге элемтә үзәге узган елның сентябреннән эшли башлады. Ул моңа кадәр сәламәтлек саклау юнәлешендә эшләп килгән барлык «кайнар линия»ләрне берләштергән. Операторлар барлык медицина оешмаларының мәгълүмат системасына тоташтырылган.

Грипп белән беррәттән коронавирус, ОРВИ котырган чорда яшибез. Инфекцияле чирләр дә тик ятмый. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марина Патяшина күптән түгел узган коллегия утырышында инфекцияле авырулар баш калкытуның төп сәбәбе дип ковид аркасында иммунитет какшауны атаган иде. Шул сәбәпле республикада 26 төрле инфекция белән авыручылар саны арткан. Аларның күбесе күпьеллык уртача күрсәткечләрдән дә артып китә икән.

– Узган ел республикада грипп йоктыру очраклары 4,5 тапкыр артты. Яңа ел башыннан бирле республикада берьюлы өч төрле вирус – грипп, коронавирус һәм ОРВИ белән авыручылар да күзәтелә башлады. Аларның саны февраль – март айларында кимер, дип өметләнәбез, – дип сөйләде идарә башлыгы.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАЛӘПЛӘР КАТГЫЙЛАНА

Сүз уңаеннан, бу көннәрдә Роспотребнадзор идарәсе ОРВИ, грипп һәм коронавирус белән авыручыларны хастаханәгә алып бару һәм дәваланырга салу буенча таләпләрне раслаган. Ул кичәге көннән үз көченә керде. Документтан аңлашылганча, әлеге төр вируслы авыруларны йоктыручылар инфекция бүлекләрендә генә дәваланырга тиеш. Сырхауханә җитәкчелеге бу чирләрнең дәвалау оешмасы эчендә кешедән-кешегә йокмавын да кайгыртырга тиеш. Авыруны сырхауханәгә алып барганда, аны озата баручы да, машина йөртүче дә битлектән булырга тиеш. Лаборатория хезмәткәрләре исә бер тәүлек эчендә Роспотребнадзор идарәсенә коронавируска тикшерү нәтиҗәләрен юлларга тиеш.

Ватан хакына

ИКӘҮ БЕРГӘ...

2023 елның 1 маенда Иске һәм Яңа Кишет авыллары туганнан туган Алмаз Сәлахиев белән Фирдүс Гариповны соңгы юлга озатты. Алар махсус хәрби операциядә һәлак була. Язмыштыр, алар бер вакытта чакырылып, бер ротага эләгәләр. Вафатларына бер атна кала ялга кайталар. Бу ике батыр егетнең хатыннары тол, икешәр баласы ятим калды. Алмазның хатыны Люция белән аралашып торсак та, Фирдүснең хәләле Гөлчәчәк белән әле күптән түгел генә таныштык. Ирләре кебек үк, икесендә дә бер язмыш бу ханымнарның.

Люция

«ВТ» коллективы махсус хәрби операциядәге егетләргә күчтәнәчләр җыя дип хәбәр бирүгә, эш кабинетыма килеп керде ул. Зур сумкага ниләр генә салмаган. Ул чакта күңелендәге ярасын кузгатасы килмәде. Әмма күзләрендәге моңсулыкны күреп, йөрәк өшеде. Әмма шулай да үзендә көч тапкан, әле бит егетләргә әнә күпме әйбер җыеп алып килгән дип калдым. Яшермим, ул чакта Люция сумкасындагы әйберләрне карап, андагыларга ни кирәген аңладык. Иренә һәм аның дусларына башта ай буе «Казан Экспо»га әйбер ташыган, аннары айга әллә ничәшәр посылка салган кеше ул. Инде ире Алмазның вафатыннан соң да егетләрне ташламый.

– Алмазны сагынмаган минутым юк. Шулкадәр акыллы, төпле фикерле кеше иде ул. Тыныч кына сөйләшер иде. Гаилә корып, ипотекага фатир алып, ике баланыз өчен сөенеп яшәгән чак иде бит. 2022 елның 24 сентябрендә повестка килде. Иремне Арчадан алып киттеләр. 24 октябрьдә Казаннан махсус хәрби операция зонасына кузгалдылар. Күңелдә кире кайтарырлар дигән уем бар иде. Бер дә югалтырмын дип яшәмәдем. Бу хакта уйламадым да, – ди Люция.

Алмаз 5 ноябрьдә алгы сызыкка кереп китә. Шуннан соң 10 көн бер хәбәре булмый. Бу вакытны ничек кичергәннәрен үзе генә белә аның гаиләсе. Мин



исән, дип хәбәре килгәч кенә, тормыш яңадан дәвам итә башлый. Әнә шул 10 көнгә югалганнан соң, мондый хәбәрсез торулар еш кабатлана. Люция ире белән бергә булган егетләрнең якыннарын эзләп таба, алар белән элемтәдә тора башлый. Тагын шунысы бар: Фирдүс белән бергә була алар. Ә бу якта – Люция белән Гөлчәчәк.

Егетләр ялга да бергә кайта. «И ул көннәрнең рәхәтлеге!» – дип искә ала Люция. Әллә үләсен сизә Алмаз, гел тормыш хакында сөйли. Киләчәктә ниләр эшлиселәрен сөйләшәләр. Киңәшләшәләр дә. Кем уйлаган шулай итеп соңгы тапкыр сөйләшеп утырырлар дип? Алмазы Люциягә гел төпле киңәш бирә: «Безнең балалар синнән һәм миннән башка кешегә кирәкми», – ди. Әнә шул сүз Люциягә ачы хәсрәтне күтәрергә булыша да инде. Иренең үлгән хәбәре киләсе көнне дә күңеле никтер авылга ашкына аның. Әтисенең туган көне дә булгангамы, бик ашыгып кайта. Алмазы берничә тапкыр шалтырата ул көнне. Соңгы сүзе: «Бабайны туган көне белән котла», – дигән була. Аннары алар смс кына язышалар. Төнге бердә Люциянең телефонына чит номер шалтырата. Таныш түгел тавыш Алмаз белән Фирдүснең һәлак булганын җиткерә.

– Өйдәгеләргә әйтү юк. Ышанмадым да әле. Машинама чыгып, тагын теге номерга шалтыраттым. Дөрес сүз булды. Аннары инде Арчага Гөлчәчәк янына киттем, – ди Люция.

Бер атнадан егетләрнең икесенең дә җәсәден алып кайталар. Шул көннән Люция ике кызына әти дә, әни дә була. Сабыйлар әтиләрен бик сагына икән. Шуңа да Люция күз яшьләрен күрсәтми. Кеше янында елмаеп, кеше юкта еларга өйрәнгән инде ул.

– Елап утырып булмый. Үзеңне үзең авырлыктан тартып чыгарырга кирәк. Мин еш кына: «Тукта, Люция, тагын елыйсыңмы?» – дим. Авыр чакта сиңа ияреп елап утыручы түгел, сине сүзе белән юатучы кеше кирәк. Минем Гөлчәчәгем бар. Икәү бергә елыйбыз, икәү бергә яшәр өчен көч табабыз. Балаларыбыз бар бит, алар өчен яшәргә кирәк, – ди Люция. – Әти-әнием, туганнарым, күршеләремә рәхмәт. Ирләребез белән бергә булган егетләрнең гаиләләре безне ташламый. Аларга да рәхмәт.

Гөлчәчәк

Алар Фирдүс белән бер авылдан. Иске Кишетнекеләр. Бер мәктәптә укып, бергә уйнап үссәләр дә, язмыш аларны 2010 елда гына очраштыра. Әле егет белән кыз булып 7 ел очрашып йөри алар. Бары тик 2017 елда гына гаилә коралар. Фирдүсне язмыш яшьли сыный. 2 нче сыйныфта укыганда ук әтисез кала ул. Гаиләдә өч бала. Иң кечесе булганга, Фирдүс әнисенең ярдәмчесенә әйләнә.

– 2018 елда кызыбыз Камилә туды. Без башта Казанда яшәдек. Аннары инде ипотекага фатир алып, Арчага күчендек. Тормышларыбыз көйләнеп беткән иде. Иремә дә повестка765ны 24 сентябрьдә тапшырдылар. Ул көнне авылга мунчага кайттык. Без кайтып күп тә үтмәде, кемдер ишек шакыды. Фирдүсне чакырып чыгардылар. Авыл җирлеге башлыгы икән. Кулына повестка тоттырып киттеләр, – дип сөйли Гөлчәчәк.

Фирдүс: «Бабай Бөек Ватан сугышыннан, Гомәр абый әфган сугышыннан исән-сау кайтты, мин дә кайтам, балаларымны ятим итмим», – ди хатынына. Алмаз белән бергә китәләр. Ул көнне өстән яңгыр явып тора. Гөлчәчәк апасы, җизнәсе белән ирен озатырга бара. Кулында – ике сабые. Улы Рамазан, шуннан кайткач, бер атна авырый.

– Ә аннары иремне алгы сызыкка керттеләр. Ун көнгә югалды. Ул көннәрне яшәмәдем дә кебек. Чит телефон номерыннан, шалтырат әле, дигән хәбәр килде. Кире җыйсам, Фирдүс. Шатлыктан елап җибәргәнемне сизми дә калдым. Аннары ияләшкән дә идек инде. 3–4 көнгә бер элемтәгә чыкса, сөенеп туймадык, – дип искә ала Гөлчәчәк. – Ялга кайтабыз дигәч, ничек көткәнне белсәгез иде. Әле бит ул аны кешегә әйтмәскә кушты. Машина белән каршы алырга кирәк. Түзмәдем, апама әйттем инде. Фирдүснең әнисен дә үзебезгә чакырдым. Әнинең ул көнне туган көне дә иде. Зур бүләк булды инде ул. Аннары үзенең туган көне дә ялда чагына туры килде. 9 апрельдә 34 яшен тутырды.

14 көн ял тиз уза. Китәр көнне Гөлчәчәк ирен Казанга ук озата бара. Фирдүс юл буе берни сөйләшми. Гөлчәчәкнең кулын тота да барып җиткәнче җибәрми. Аерылышканда: «Елама, мин кайтам», – ди. Кайта ул. Тик үз аяклары белән түгел.

– Һәлак буласы көнне Фирдүс элемтәгә чыга алмады. Люциягә яздым. Ул Алмаз белән сөйләшкән булган. Шуннан соң тынычландым. Балалар уянмасын дип, телефонның тавышын кысып куеп, йокларга яттым. Төнге берләр тирәсендә күршеләргә ишек шакыган тавышка уянып киттем. Карасам, телефонымның уты яна. Люция икән. «Ач әле ишегеңне. Мин бу. Безнекеләр харап булган», – диде. Бик авыр кичердек. Люция белән хәлебезне икебез генә беләбез, – ди Гөлчәчәк. – Төрле сүзләр ишеттек. Акчабызны санаучылар да булды. Их, ике балама акча тоттырып, бу – сезнең әтиегез, дип булмый шул... Аларга әти кирәк. Хәлемнән килсә, бар акчасын кире илтеп, үзен алып кайтыр идем. Исән генә булсын иде...

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Казан шәһәре Идел буе районыннан сигез бала анасы **Ибраһимова** Исламия Гомәр кызы **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Әлмәт муниципаль районы буенча Яңа Нәдер авылыннан алты бала анасы **Мөхәммәтҗанова** Гөлнара Рафикъ кызы, Арча муниципаль районы буенча Арча шәһәреннән биш бала анасы **Закирова** Раушания Наил кызы, Түбән Кама муниципаль районы буенча Түбән Кама шәһәреннән биш бала анасы **Хисмәтуллина** Анна Наил кызы, Саба муниципаль районы буенча Килдебәк авылыннан биш бала анасы **Кәримуллина** Алия Рафаэль кызы, Казан шәһәренең Идел буе районыннан биш бала анасы **Лоханова** Анастасия Александровна, Казан шәһәренең Идел буе районыннан биш бала анасы **Сафиуллина** Лилия Дамир кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «18 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең участок табиб-терапевты **Әхмәтова** Ләйсән Илдар кызына, «Актаныш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең гомуми практика табибы (гаилә табибы) **Ибраһимова** Рифә Сәнәф кызына, «Аксубай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Иске Ибрай амбулаториясе терапия кабинеты гомуми практика табибы (гаилә табибы) **Минугулов** Галимҗан Гомәр улына, «Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлекчәсе мөдире – табиб-инфекционисты **Подряднова** Татьяна Валентиновнага, «Теләче үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең участок табиб-педиатры **Шакирова** Ләйлә Марсель кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 3 номерлы поликлиникасы 3 номерлы педиатрия бүлекчәсе участок табиб-педиатры **Шәнгәрәева** Илсөяр Камил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы өлкән шәфкать туташы **Андреева** Ирина Алексеевнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Әлмәт шәһәрендәге филиалы баш табибы **Мортазин** Әсгать Камил улына, «Әлки муниципаль районының Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ашыгыч медицина ярдәме бүлекчәсе фельдшеры **Оспенникова** Любовь Константиновнага, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе функциональ диагностика бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы **Сәмитова** Лилия Фәем кызына, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе санитария-химия һәм токсик-гигиена тикшеренүләре бүлегенең физик-химик тикшерү ысуллары лабораториясе табибы-лаборанты **Угричич-Требинский** Всеволод Викторовичка **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Арабыздан беребез

Күңел түрендәге сөенеч

Мөслим районының Елгабаш авылында зур бәйрәм бүген. Юк, монда сүз ниндидер күңел ачу чаралары турында гына бармый әле. Әлбәттә инде, алардан башка да булмас. Авылдашлары «Елабугадорстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең хуҗасы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган төзүчесе Рәшит Хәбировның юбилеен – 65 яшь тулган көнен матур бер вакыйга итеп кабул итә. Аңа исәнлек теләп, күңел түрендә сөенеч йөртә. Чөнки башкача мөмкин дә түгел. Рәшит Галәү улы 400 ел элек нигез салынган тарихи туган авылын гөлбакча итте.

Тарихи дигәннән, Елгабашның 400 еллык юбилеен моннан берничә ел билгеләп үткәннәр иде елгабашлылар. Рәшит Галәү улы шушы уңайдан авыл тарихын яздыртып, китап чыгарды, авылдашларына бүләк итте. Хезмәт алдынгыларына кыйммәтле бүләкләр тапшырды. Һәр гаиләгә күчтәнәч өләште. Бабалары урынны сайлый белгән: гаҗәеп матур җиргә урнашкан аларның авылы. Ул вакытта шушы җирдән чыккан, республикабызның төрле почмакларыннан килгән биш меңләп кунак кабул иткән иде Елгабаш. Авылдашлары Рәшит Хәбировка рәхмәт әйтә-әйтә, бездән дә өлеш керсен дип, һәрберсе йорт тирәсен яңарткан, чәчәкләр утырткан иде.

Рәшит Хәбировны белмәгән кеше юк бу авылда. Әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да бабалары хәлле кеше булып, авылдашларына, мохтаҗларына ярдәм итеп яшәгән. Нәселдәге бер тармак вәкилләре күп еллар буена указлы мулла вазыйфасын башкарган. Рәшит үзе 7 яшеннән әтисез калып, авырлыкта үссә дә, Нәсиха апа балаларына яхшы тәрбия бирә алган. Улы ата-бабаларыннан калган иң күркәм сыйфатны югалтмаган: авылдашларына ярдәм итүне ташламый. Эшләрен, чыннан да, санап бетерерлек түгел. Хәләл акчасына мәчет салдырган, зират тирәсен тоттырган, авылны газлаштыру, юлларга асфальт түшәү артыннан йөреп, аларны да хәл иткән. Үз хисабына мәдәният йорты, ашханәсе белән башлангыч мәктәп, процедуралар кабинеты белән медицина пункты, китапханәсе, бильярд залы булган күпфункцияле бина салдырып, аны тулысынча җиһазлап, авылдашларына бүләк иткән. Ел саен Сабантуйлар үткәрүне дә үз өстенә ала ул. Батырларга хәтта чит ил машинасы бүләк иткән чаклары да була.

Иң мөһиме, бу изге эшләрне башкарганда аңа гаиләсе төп терәк булып тора, балалары ярдәмгә килә. Димәк, нәсел-нәсәпкә хас булган гореф-гадәтләр дәвам итә дигән сүз бу.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасының Сарман муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты, Сарман районында озак еллар җитәкче урыннарда эшләгән **ГАФУРОВ Ирек Баһаутдин улының** вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсенең кайгысын уртаклаша.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65, 222-09-70.

E-mail: vtreklama@mail.ru

Бәйрәм уңаеннан

Сагындыра студент еллары

Иртәгә, 25 гыйнвар – Бөтенроссия студентлар көне. Студент еллары – яшьлекнең бер гүзәл чоры, шул ук вакытта кешене олы тормышка әзерләүче бер этап та. Ә сезнең өчен әлеге иң күңелле һәм онытылмас вакыт нәрсәсе белән истәлекле һәм кадерле?

Булат БӘЙРӘМОВ, җырчы, алып баручы:
– Минем студент еллары бик озак – 8 ел дәвам итте. Башта Арча педагогия көллиятендә биш ел укыдым. Аннан соң өч ел Казанда. Яшьлекнең иң күңелле, иң истә калган чаклары бу. Әйтик, көллияттә укыган вакытта бәрәңгегә барулар. Башта әле бер ай укымыйсың, шунда эшлисең. Үзеңне сәхнәдә тоту, җырлау, сөйләү ягыннан да Арча көллияте зур мәктәп, бик яхшы тәҗрибә булды. Бергә укыган төркемдәшләр белән ел саен очрашып торабыз. 1999 елда Татар дәүләт гуманитар педагогика университетының музыка факультетына укырга кердем. Казанда уку Ләйсән белән танышу буларак истә калды. Аның белән бер хорда җырладык, бер тулай торакта яшәдек. Икенче курста укыганда бер ел мәктәптә эшләп алдым, өченче курста радиога эшкә кердем. Укуга әзерләнеп килә торган студент, болтун идем инде *(көлә)*. Укытучыларны бүлдерә идем, аның өчен эләгә дә иде миңа. Тынгысызрак һәм хәйләкәр идем. Әйтик, дәрескә иртән әзерләнеп киләм дә, җавап бирүчеләр булмаса, үзем кул күтәреп, шалт итеп җавап биреп куям. Аннан соң берничә дәрес әзерләнмичә йөри идем. Ул вакытларда Ләйсән дә шаккаткан иде миңа.

Мөхәррәм МӨХӘММӘТҖАНОВ, агроном:
– Дүрт ел ярым Тәтеш техникумында, җиде ел Казанда авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укыдым. Тәтештә студент булып йөргән елларда айга икешәр тапкыр, бигрәк тә бәйрәм тирәләрендә 55 чакрым ераклыктагы өемә, әнкәй, энеләрем яшәгән туган авылга кайта идем. Кыш көннәрендә җәяү я булмаса трактор чанасында. Аннан техникумнан ботинкалы чаңгы бирделәр, шуның белән кайтып йөрдем. Җәен спорт велосипеды белән кайта идем. Дүшәмбе укырга да барып өлгерәм. Бик арытса да, ял булды ул миңа, авылга кайткач, күңел тынычлана иде. Уку вакытында дәрес әзерләүне белмәдем. Укытучы аңлатуы китапка караганда башка ныграк кереп утыра иде. Имтихан алдыннан якын дусларым, олы яшьтәге студентлар белән бергә әзерләндек. Студент тормышы кызык инде. Күп җирдә катнаштым. Актив, кызыксынучан идем. Заманалар да икенче иде. 1960 нчы еллар студенты буларак, кулга беренче акчаны (стипендия 14 сум иде) алдык. Ашарга тәүлеккә ярты буханка кукуруз ипие генә иде. Менә шундый иде студент елларым.

Илсөяр ИХСАНОВА, шагыйрә:
– Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укыдым. Ул үзе бер мәктәп, аерым бер дөнья иде. Безнең төркемне зур галимә Диләрә Тумашева җыйды. Студент еллары дигәндә, иң беренче аның лекцияләре, Мөхәммәт Мәһдиев, Флера Сафиуллина, Хатыйп Миңнегуловның лекцияләре искә төшә. Алар безгә бөтенләй яңа дөнья ачты. Студент еллары тулай торактагы тормыш белән дә истә калды. Иң якын дуслар да шушы вакытта табылды. Гомер буе миңа терәк булган якын кешеләрем – Гөлфинә Гатауллина, Дания Заһидуллина, Ркаил Зәйдулла. Без бер мәдәни чараны калдырмый йөри идек. Премьерага эләкми калсаң, ул инде бер фаҗига кебек кабул ителде. Бөтен татар театрлары премьераларына, опера театрына йөрдек, Зур концертлар залында симфоник оркестр чыгышларын тыңладык. Ул вакытта акча юк, билетлар кыйммәт, ләкин юлын табып, барыбер бара идек. Шул студент елларында аралашкан, табышкан кешеләр гомерем буена янымда булды, бер-беребезне аңлап яшәдек. Бүген бергә уртак эшләр эшлибез, татар дөньясына хезмәт итәбез. Студент еллары алдагы тормышка ныклы бер нигез булды.

Ралинә СӘЛИМОВА, блогер, 23 яшь:
– Казан федераль университетының журналистика бүлеген тәмамладым. Минем өчен студент еллары яңа дуслар табу, шәхес буларак үсү, кеше белән аралашырга, мөстәкыйльлеккә өйрәнү чоры булды. Ул еллар әнә шунысы белән кадерле. Дус кызлар белән кәеф-сафа да кордык, бергә укыдык, эшкә өйрәндек, кирәкле тәҗрибә тупладык. Студентлык вакыты – шәхси үсеш кенә түгел, гашыйк та була торган чор. Беренче курста укыганда мәхәббәтемне – булачак иремне очраттым. Дүртенче курста укыганда аңа кияүгә чыктым.

Ләйсән САФИНА

КЕЛӘМ КҮРСӘТЕР

Газетабыз турниры

Татарның иң көчле көрәшчеләре келәмгә чыгарга әзерләнә. Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган көрәш турнирының 61нчесе 2–3 февральдә Казанда уза.

1964 елның көзендә Казанның «Динамо» җәмгыяте спорт залында үткәрелгән тәүге ярышта 11 командадан иллеләп көрәшче катнашкан. Икенче елны исә командалар саны – 24кә, ә катнашучылар саны 91гә җиткән. 1966 елда исә 30 районнан 121 пәһлеван җыелган, шулай итеп, аларның саны гел артып барган. Узган елгы 60 нчы бәйгедә 45 команда һәм 350дән артык көрәшче катнашты. Үз ишләре арасында җиңүче булып Алексей Абрамов (Лаеш), Илнар Закиров (Чистай), Ислам Фәлахов (Алабуга), Динар Кәримуллин (Лаеш), Эмиль Мавлин (Теләче), Ренас Кәлимуллин (Теләче), Раил Сәлахетдинов (Лаеш), Булат Мусин (Казан), Раил Нургалиев (Теләче), Радик Сәлахов (Лаеш) һәм Ранис Гыйлаҗетдинов (Чаллы) танылды. Быелгы исемлектә кемнәр урын алыр? Узган елгы җиңүчеләрдән икесе генә үз титулын саклап калган еллар булды.

Командалар беренчелеген узган ел Лаеш егетләре отты. Чаллы – икенче, Теләче өченче булды. Алар быел да газетабыз Кубогы өчен көрәшәчәк. Әле бит Әлмәт бар, Арча, Балтач, Кукмарада көчле егетләр яши, Чистай өчен бил алышучы көрәшчеләр дә үзен күрсәтергә тырышачак. Дөрес, командалар составындагы үзгәрешләр дә сизелми калмас. Әйтик, узган ел Лаеш данын яклаган Илмир Төхвәтуллин рәсми ярышлардагы чыгышын туктатты. Җәлил бәйгесендә дүрт мәртәбә җиңү яулаган Радик Сәлахов кабат Зәй командасы өчен бил алыша башлады.

Әмма газетабыз турнирының мәгънәсе иң көчлеләрне ачыклау белән генә чикләнми. Беренчедән, биредә элеккеге батырларны хөрмәтлиләр, бакыйлыкка күчкәннәрне искә алалар. Бәйгенең исеме дә батырлык һәм үткәнебезгә бәйле бит. Икенчедән, Җәлил турниры алдыннан көрәш җәмәгатьчелеге узган елга нәтиҗә ясый, алга таба кая барасыбыз турында киңәшләшә. Шуңа күрә оештыручылар да, көрәшчеләр дә дәрәҗәне төшермәскә тырыша.

Җәлил турниры турында 7 факт

- Турнирның беренчесе Казанда уза. Татарстан башкаласында ул барлыгы 31 мәртәбә оештырыла. Муса Җәлил бәйгесе Чаллыда – 12, Әлмәттә – 4, Зәй һәм Биектауда 3әр мәртәбә оештырыла. Барлыгы 11 шәһәр һәм районда.
- Беренче турнирда Сарман көрәшчеләре җиңеп чыккан. Аннан соң Күчмә кубок Буага киткән, соңрак Чистайга ук барып җиткән. Бу ярышны чаллылылар – 9, әлмәтлеләр – 7, түбәнкамалылар 5 тапкыр откан. Рекорд исә – Балтачта. Алар бу бәйгедә 13 мәртәбә җиңү яулый. Турнир тарихында 70тән артык команда катнашкан.
- 1964 елда узган тәүге бәйгедә Зөфәр Ханов (Сарман), Габдулла Ямалов (Сарман), Талип Яруллин (Әлки), Габдулла Хафизов (Чаллы) җиңеп чыга.
- Чаллы батыры Айрат Гыйлаев бу бәйгедә 12 тапкыр җиңде. Балтачтан Айдар Хәйретдинов 10 мәртәбә батыр калды. Узган ел Теләчедән Раил Нургалиев та җиңүләрен бер дистәгә тутырды. Ильяс Галимов (Әлмәт) бәйге тарихына 9 мәртәбә уңышка ирешкән батыр булып кереп калды. Балык Бистәсеннән Илнар Әхмәтҗанов та бу ярышта 9 мәртәбә җиңү яулады. Теләчедән Ренас Кәлимуллинның 8 җиңүе бар.
- Бәйгедә ике тапкыр җиңүгә ирешкән Балтач егете Сәйдәш Мәгъсүмов 1983 елда батыр исемен яулаганда әле 18 яшен тутырмаган була. 1964 һәм 1968 елларда батыр калган Сарман егете Зөфәр Ханов исә икенче җиңүенә 45 яше тулып килгәндә ирешә.
- Муса Җәлил истәлегенә узучы турнирда герой-шагыйрьнең адашы Муса Галләмов биш мәртәбә җиңүче булды.
- Турнир тарихында авырлык категорияләре үзгәреп торган. 1964–1970 елларда аларның саны – дүрт, 1971–1981 елларда – биш, 1982–1994 елларда – тугыз, 1995–2005 елларда – ун, 2006–2007 елларда – янәдән тугыз, 2006–2022 елларда ун булган. Икенче ел рәттән көрәшчеләр 11 авырлык категориясендә бил алыша.

Айрат ГЫЙЛАЕВ, бәйгенең 12 мәртәбә җиңүчесе (Чаллы):

Иң яраткан ярышым, иң зур турнир ул минем өчен. Гәрчә хәзер дөнья чемпионатлары узса да. Миңа бу ярышта һәрвакыт уңыш елмайды. Бәлки, әзерлек яхшырак булгандыр. Көзге ярышларга килгәндә, җәйге ялдан соң әзерлек җитмәгән, күрәсең. Ә Җәлил турнирында исә бар көчемне күрсәтергә тырыша идем. Кайсы җиңү истә калды дигәндә, әлбәттә, беренчесен онытып булмый. Тагын берсен яхшы хәтерлим әле. Анысы ахырга таба булды. Бер атна кала Азнакайда билбаулы көрәш буенча Татарстан чемпионаты узды. Йә әйтегез, кем инде Җәлил турнирына бер атна кала зур ярыш оештыра? Кыскасы, Азнакайдан грипп эләктереп кайттым. Гомергә ятып авырганым юк иде. Монысында ике көн юрган астыннан чыга алмадым. Тегеләй итеп, болай итеп, ничек тә аякка басарга, келәмгә чыгарга туры килде. Ничек отып чыкканмындыр – әле дә аңлый алмыйм.

Мөнәсәбәт

АЛДАУ һӘМ АЛДАНУ

ФОНОГРАММАГА КУЕЛГАН КОНЦЕРТЛАРНЫ ДЕПУТАТЛАР ДА ТИКШЕРМӘКЧЕ

«Тере» тавыш, «тере» музыка... Бүгенге татар эстрадасы өчен шактый тансык төшенчәләр бу. Җырчыларга да, хәтта тамашачыларга да шоу, динамика, тышкы кыяфәт – кыскасы, концертның «кабыгы» мөһим. Шуңа бүген фонограммага җырлау гадәти күренешкә әйләнде. Ләкин бу тамашачыны алдау булмыймы?

Кемгә? Нәрсә? Ни өчен?

Фонограммага куелган концертларны хокукый яктан тикшерергә тәкъдим итәләр. Әйтик, Башкортстан депутатларының бу мәсьәләне язгы сессия вакытында күтәрергә җыенуын яза «Парламентская газета». Фонограммага җырлауны тамашачыны алдау дип саный алар. Хәер, мондый тәкъдим 2013 елда Россия Дәүләт Думасында да яңгыраган булган. Ул чакта концертка чакыра торган афишаларда фонограмма файдалану турында мәгълүмат, ягъни маркировка булырга тиешлеге язылган закон проекты тәкъдим ителгән. Андый мәгълүматны язып тормыйча, фонограмма файдаланылган концертны оештыручыга штраф салу, ә тамашачыга билет бәясен кайтару да күз уңында тотылган анда. Ләкин документ кабул ителмәгән. Менә быел тагын бу инициативага әйләнеп кайтмакчылар.

«Аларга сәнгать кирәк!»

Әлеге кыйссаның төп геройлары – җырчылар үзләре бу хакта ни уйлый икән соң? Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинова мондый яңалыклардан курыкмый.

– Башка җырчыларда эшем юк. Ләкин кем ничек булдыра ала, шулай эшли. Бөтенебез тырышабыз, – ди ул. – Үзем фонограмманы тыюдан һич тә курыкмыйм. Ә менә аранжировканы тыйсалар, эстрада бетәчәк! Алай-болай артистлар өчен «нормальный» гримеркалар, техника куеп була торган әйбәт концерт заллары да төзиселәре килмиме икән?

Фонограммага җырлап, татар җыр сәнгатен үстереп булмый. Татарстанның халык артисты Филүс Каһиров әнә шундый фикердә.

– Фонограммага җырлау җәһәтеннән фикеремне күптән әйтеп киләм. Әйтеп кенә түгел, эш белән дә күрсәтәм. Без концертларда хәтта «минусовой» аранжировкаларны да (ягъни электрон музыкага кушылып, артист үзе җырлый) бик сирәк кулланабыз. Әйтик, быелгы концертта 3–4 җырны гына шулай башкардык. Калганнарын – бары оркестр һәм «тере» тавыш белән генә, – диде ул. – Кайбер артистлар: «Синең өчен аермасы нәрсәдә аның?» – ди. Тамашачыны алдау ул, мин әйтәм. «Мине тере килеш күрәләр – аларга шул кирәк бит», – диләр. Юк, мин әйтәм, аларга сәнгать кирәк! Фонограммага җырлап, татар җыр сәнгатен үстереп булмый.

«Селкетер» дип уйламыйм...»

«Фонограммага җырлау = тамашачыны алдау» фикере белән журналист Альберт Шакиров та килешә. Әмма искәрмәләр дә булырга мөмкин дип саный ул.

– Әгәр дә аны чикләргә, башка продукциягә маркировка куйган кебек концертларны, чыгышларны да маркировкаларга уйлыйлар икән, бик хуп. Ләкин искәрмәләр дә булырга мөмкин. Әйтик, артистның физик халәте. Концертны, тамашаны да берничек кичектереп тә, шул ук вакытта җырлап та булмаган чакта артистны аңларга була. Яки стадион ише зур залда чыгыш ясарга туры килеп, оештыручыларның техникасы «тере» тавышка исәпләнмәгән булса да, фонограммага җырлауны кичерергә була. Калган очракта – юк, – диде ул.

Кызганыч, бүген тамашачы үзе дә фонограммага ияләнеп бетте. Алдан яздырылган, кытыршы урыннары чистартылган җырны тыңлау рәхәтрәктер, бәлки. Альберт Шакиров та шулай ди.

Яшерен-батырын түгел, хәзер җырлый белгән артистлар да, белмәгәннәре дә концерт куя. Концерт-тамашаларга йөрү тәҗрибәсе зур булган хезмәттәшебез Чулпан Гарифуллина сүзен шуннан башлады.

– «Тере» тавыш белән җырлый алырга сәләтле җырчылар аз хәзер. Дөресен әйтик, андыйларның концертларына тамашачы да бик ашкынып йөрми. Фонограммага җырлауны мин дә алдау дип саныйм. Ә инде бу тәкъдимнәрдәгечә, җырчылар, фонограммага җырлыйбыз, дип алдан кисәтә икән, билет бәясен төшерәләр икән, мин риза. Әлбәттә, бер җырчы да алай эшләмәячәк, һәм берни дә үзгәрмәячәк. «Бу – безнең эшебез, болай итәргә кирәкми, билет бәясен төшерә алмыйбыз, безгә бит зал арендаларга кирәк», – ише сүзләр яңгырый башлаячак җырчылар тарафыннан, – ди ул. – Халык үзе дә фонограммага ияләнеп килә бит. Бүген аңа җырчының ничек җырлавы түгел, кыяфәте, сәхнәдә тотышы, социаль челтәрләрдәге тормышы мөһимрәк. Шуңа да бу тәкъдимнәр тамашачыны да, җырчыларны да «селкетер» дип уйламыйм.

Фикер

Дмитрий ПЕВЦОВ, Россия Дәүләт Думасының Мәдәният буенча комитеты рәисенең беренче урынбасары:
– Фонограммага җырлау – тамашачыны алдау. Миңа калса, бу артистның сәхнәдә тулысы белән булмавын аңлата. Ягъни артистның сәхнәдә гәүдәсе генә бар, тавышы юк. Тамашачыга карата гадел булырга кирәк.

Законнар «фонограмма» төшенчәсенә конкрет билгеләмә бирми һәм аны киң итеп аңлата. 2013 елда теге карар кабул ителмәвенең дә төп сәбәбе шул булган. «ВТ» юристы Булат Закиров бу мәсьәләнең хокукый ягын менә ничек аңлата:

– Фонограммалар куллануны көйләү, беренче чиратта, авторлык хокукларын яклау өчен башкарыла. Бу контекстта фонограммалар куллануны көйләү гражданнарның хокукларын яклау максатында тәкъдим ителә. Законга нинди үзгәрешләр кертергә ниятләүләре әлегә төгәл билгеле түгел. Әгәр нәтиҗәдә концертта фонограмма кулланылачагы алдан хәбәр итү турында карар кабул ителсә, бу, һичшиксез, тамашачы өчен уңай яңалык булачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2042 данә
Гомуми тираж – 11230 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 208

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+